КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 12 август г.Казань № 568

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 декабрь, 1063 нче; 2015 ел, 8 май, 333 нче; 2015 ел, 17 июнь, 444 нче; 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы; 2016 ел, 30 март, 181 нче; 2016 ел, 25 май, 349 нчы; 2016 ел, 13 сентябрь, 640 нчы; 2016 ел, 21 сентябрь, 670 нче; 2016 ел, 28 ноябрь, 877 нче; 2017 ел, 25 гыйнвар, 29 нчы; 2017 ел, 28 апрель, 254 нче; 2017 ел, 26 июнь, 430 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә һәм 1 пунктында һәм Программа исемендә «2014 – 2020 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

Программа паспортында:

Программа паспорты исемендә «2014 – 2020 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

«Программа исеме» юлында «2014 – 2020 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

«Программаны тормышка ашыру вакытлары» юлында «2014 – 2020 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

«Ярдәмче программалар исемлеге» юлында 7 пунктны түбәндәге реакциядә бәян итәргә:

«7. 2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкенең социаль һәм инженер инфраструктурасын үстерү»;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп Программаны финанслау күләмнәре» юлына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2021 – 2025 елларга» акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»;

«Еллар буенча бүлеп программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)» юлында беренче абзацта «2020 елга» сүзләрен «2025 елга» сүзләренә алмаштырырга;

Программаның 2 бүлегендә:

егерме бишенче абзацта «2014 – 2020 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

Программаның 3 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2021 – 2025 елларга» акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»;

«Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкенең социаль һәм инженер инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – Ярдәмче программа):

Ярдәмче программа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженер инфраструктураны үстерү»;

Ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары», «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре», «Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары)» юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары | 2014 – 2025 еллар |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программа чараларын финанслау күләмнәре 65 220 585.03 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге |

| | |
|---|---|
| | еллар буенча:<br>2014 ел – 3 276 380,3 мең сум;<br>2015 ел – 10 287 192,8 мең сум;<br>2016 ел – 12 319 020,9 мең сум;<br>2017 ел – 11 284 218,43 мең сум;<br>2018 ел – 9 960 996,1 мең сум;<br>2019 ел – 8 910 996,1 мең сум;<br>2020 ел – 1 906 155,2 мең сум*;<br>2021 ел – 1 925 454,4 мең сум*;<br>2022 ел – 1 875 272,8 мең сум*;<br>2023 ел – 1 282 280,0 мең сум*;<br>2024 ел – 1 264 790,0 мең сум*;<br>2025 ел – 927 828,0 мең сум*.<br>* 2020 – 2025 елларга акча күләмнәре фараз характерында була һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә |
| Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары) | Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2025 елга түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрнең гомуми санында мәктәпкәчә белем стандартлары таләпләренә туры килә торган программалар буенча укучы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрнең чагыштырма авырлыгын 100 процент дәрәҗәсендә саклау;<br>төрле оештыру-хокукый формадагы һәм милек формасындагы оешмаларда мәктәпкәчә белем бирү хезмәтен күрсәтүне һәм (яки) аларны карап тоту хезмәтен алучы 3 яшьтән 7 яшькәчә балалар өлешен 98 процентка кадәр арттыру;<br>яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә укучы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының чагыштырма авырлыгын 98 процентка кадәр арттыру;<br>биналары авария хәлендә булган яки капиталь ремонт таләп ителгән дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү оешмалары һәм балалар даими булган дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү оешмалары санын 63 берәмлеккә кадәр киметү;<br>гомуми белем бирү оешмаларының гомуми санында инвалид балаларга инклюзив белем |

| | |
|---|---|
| | бирү өчен универсаль каршылыксыз мохит тудырылган гомуми белем бирү оешмалары өлешен 22,9 процентка кадәр арттыру;<br>мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының гомуми санында инвалид балаларга инклюзив белем бирү өчен универсаль каршылыксыз мохит тудырылган мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өлешен 18 процентка кадәр арттыру;<br>1,5 яшьтән 7 яшькәчә инвалид балаларның гомуми санында мәктәпкәчә белем бирү белән колачланган бу яшьтәге балалар өлешен 100 процент дәрәҗәсендә саклау;<br>мәктәп яшендәге инвалид балаларның гомуми санында сыйфатлы башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алу өчен шартлар тудырылган инвалид балалар өлешен 100 процент дәрәҗәсендә саклау;<br>5 яшьтән 18 яшькәчә инвалид балаларның гомуми санында өстәмә белем алучы бу яшьтәге балалар өлешен 50 процент дәрәҗәсендә саклау;<br>Россия Федерациясе субъектында мәгариф оешмаларының гомуми санында инвалид балаларга сыйфатлы белем алу өчен шартлар тудырылган мәгариф оешмалары өлешен 15,5 процент дәрәҗәсендә саклау;<br>инвалид чыгарылыш укучыларның гомуми санында һөнәри юнәлеш бирү эше белән колачланган 9 һәм 11 сыйныфны тәмамлаучы инвалидлар өлешен 100 процентка кадәр арттыру;<br>2020 елга гомуми белем бирү оешмаларының 1 – 4 һәм 10 – 11 (12) сыйныфларында уучыларның барысын да беренче сменада укуга күчерү;<br>202 елга мәктәпләрне 70 проценттан артык тузган биналардан яңа биналарга күчерү;<br>гомуми белем бирү оешмаларында гамәлдәге бер сменалы уку режимын саклау;<br>2025 елга гомуми белем бирү оешмаларында яңа 22126 урын гамәлгә кертү;<br>2025 елга мәктәп биналарын төзү исәбенә 36 яңа гомуми белем бирү оешмасын гамәлгә кертү;<br>гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми санында бер сменада |

| | |
|---|---|
| | шөгыльләнүче укучылар санының чагыштырма авырлыгын 100 процентка кадәр арттыру;<br>гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми санында бер сменада шөгыльләнүче башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучылар санының чагыштырма авырлыгын 100 процентка кадәр арттыру;<br>гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми санында бер сменада шөгыльләнүче төп гомуми белем бирү программалары буенча укучылар санының чагыштырма авырлыгын 100 процентка кадәр арттыру;<br>гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми санында бер сменада шөгыльләнүче урта гомуми белем бирү программалары буенча укучылар санының чагыштырма авырлыгын 100 процентка кадәр арттыру;<br>2017 елга спорт залларына ремонт ясалган авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары санын 14 берәмлеккә арттыру;<br>Россия Федерациясе субъектында яшәү урыны, социаль һәм мөлкәти статусы, сәламәтлеге торышы, социальләштерү модельләре һәм программалары белән колачлау категорияләре буенча балаларның гомуми санында әлеге категорияләр буенча балалар өлешен 93 процентка кадәр арту;<br>тулай торакка мохтаҗларның гомуми санында тулай торак белән тәэмин ителгән укучыларның чагыштырма авырлыгын 90 процентка кадәр арттыру;<br>һөнәри белем бирү оешмаларының гомуми санында аларны матди-техник тәэмин итүдә эш бирүче оешмалар катнаша торган һөнәри белем бирү оешмалары өлешен 75 процентка кадәр арттыру;<br>икътисадта эшләүче 25 – 65 яшьләрдәге халыкның гомуми санында һөнәри уку узган әлеге яшь төркемендәге халык санының чагыштырма авырлыгын 50 процентка кадәр арттыру; |

| | |
|---|---|
| | урта һөнәри белем бирү программалары буенча укырга кабул ителгән инвалидлар өлешен (узган елга карата) 107 процентка кадәр арттыру;<br>урта һөнәри белем бирү программалары буенча укыган, академик өлгермәү сәбәпле төшеп калган инвалидлар арасыннан студентлар өлешен 7 процентка кадәр киметү;<br>2014 елда булган аудиторияләре физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен спорт залларына яңадан профильләнгән авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны кимендә 1 берәмлек булу;<br>2017 елга укучыларның гомуми санында, мәктәпкәчә белем бирүдән тыш, дәрестән тыш вакытта физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр өлешен (башлангыч гомуми белем) 1,3 процентка арттыру;<br>2017 елга укучыларның гомуми санында, мәктәпкәчә белем бирүдән тыш, дәрестән тыш вакытта физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр өлешен (төп гомуми белем) 1,9 процентка арттыру;<br>2017 елга укучыларның гомуми санында, мәктәпкәчә белем бирүдән тыш, дәрестән тыш вакытта физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр өлешен (урта гомуми белем) 1,6 процентка арттыру;<br>2017 елга авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен төзелгән мәктәп спорт клублары санын ел саен 11 берәмлеккә арттыру;<br>2014 елга авыл җирлегендә урнашкан, аларда ачык яссы корылмалар спорт инвентары һәм җиһазлары белән җиһазландырылган гомуми белем бирү оешмалары саны кимендә 72 берәмлек булу;<br>Россия Федерациясе субъектлары гомуми белем бирү оешмаларында федераль бюджет акчасыннан финанслашу исәбеннән гамәлгә кертелгән яңа урыннар саны кимендә 2 948 берәмлек булу;<br>гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми санында өченче сменада |

| | |
|---|---|
| | шөгыльләнүчеләрнең чагыштырма авырлыгын 0 процентка кадәр киметү;<br>2017 елда капиталь ремонт яки төзекләндерү таләп ителгән биналарда шөгыльләнүче укучыларның чагыштырма авырлыгын 8,9 процентка кадәр киметү;<br>барлык төр уңайлыклары булган биналарда укучыларның чагыштырма авырлыгын 98,99 процентка кадәр арттыру»; |

Ярдәмче программаның 2 бүлегендә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Укытуның фаразланган ихтыяҗы һәм заманча шартлары нигезендә гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыру («2016 – 2025 елларга Россия Федерациясе субъектларында гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыруга (фаразланган ихтыяҗдан чыгып) булышлык күрсәтү» дәүләт программасын тормышка ашыру).

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең («2016 – 2025 елларга Россия Федерациясе субъектларында гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыруга (фаразланган ихтыяҗдан чыгып) булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслый торган  2015 ел, 23 октябрь, 2145-б боерыгын үтәү өчен, шулай ук Татарстан Республикасында сыйфатлы белем алу өчен шартлар формалаштыру максатларында уку эшчәнлегенең барлык төрләрен бер сменалы укуда оештыру мөмкинлеген, аларны гамәлгә ашыруның куркынычсызлыгын һәм уңайлыгын тәэмин итү зарурлыгы бар.

Ике сменада укыту, сыйфатлы белемнең һәркем ала алырлык булуын, укучыларның дәрестән тыш эшчәнлек төрләрен оештыру мөмкинлеген, балаларга өстәмә белем бирү хезмәтләрен сыйфатлы күрсәтүне киметеп, гомуми белемнең федераль дәүләт мәгариф стандартларын сыйфатлы итеп тормышка ашырырга мөмкинлек бирми. Шуны билгеләп үтәргә кирәк, Татарстан Республикасында дәресләрне өч сменада алып баручы мәктәпләр юк.

Укучының физик, психологик һәм социаль сәламәтлеген саклау һәм ныгытуны гарантияләүче, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем максатларына ирешүне, аның югары сыйфатын тәэмин итүче белем бирү мохиты тудыру югарыда әйтелгән федераль программаны тормышка ашыру нәтиҗәсе булып тора.

Гомуми белемнең санап кителгән баскычларының һәрберсе буенча төп белем бирү программасы мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан дәрес һәм дәрестән тыш эшчәнлек аша тормышка ашырыла. Гомуми белем бирү оешмасының дәрестән тыш эшчәнлеге 11 ел эчендә 3800 сәгать тәшкил итә.

Шулай ук гомуми белем бирү оешмасының белем бирү һәм административ-хуҗалык эшчәнлекне тәэмин итү өчен кирәкле барлык төр уңайлыклары булырга тиеш: уку бүлмәләре (шул исәптән заманча предмет кабинетлары, лабораторияләр, уку остаханәләре), мәгълүмат-китапханә, спорт бүлмәләре, дәрестән соң эшчәнлек, түгәрәкләр һәм секцияләрдә шөгыльләнү өчен бүлмәләр, шулай ук туклану оештыру өчен, медицина билгеләнешендәге бүлмәләр, административ бүлмәләр һәм кирәкле

җиһазлар белән, шул исәптән сәламәтлекләре мөмкинлеләре чикләнгән балаларга белем бирү эшчәнлеген оештыру өчен җиһазландырылган бүтән бүлмәләр.

Татарстан Республикасында 2015/2016 уку елында 1 417 мәктәп эшли, аларда 377 254 укучы белем ала. Моның белән бергә 135 мәктәптә дәресләр ике сменада оештырылган (2014/2015 уку елында – республиканың 140 мәктәбендә).

Татарстан Республикасында 2016/2017 уку елында 1 406 мәктәп эшли, аларда 387 324 укучы белем ала. Моның белән бергә 139 мәктәптә дәресләр ике сменада оештырылган (узган елда – республиканың 135 мәктәбендә).

Укулар ике сменада оештырылган мәктәпләрнең күбесе шәһәрләрдә урнашкан, шул исәптән:

62 мәктәп – Казан шәһәрендә;

15 мәктәп – Чаллы шәһәрендә;

7 мәктәп – Түбән Кама муниципаль районында,

8 мәктәп – Зеленодольск муниципаль районында,

10 мәктәп – Чистай муниципаль районында.

Ел саен мондый мәктәпләр саны кими бара (2010 елдан – 174 тән 135 кә).

Республикада 27 муниципаль районда укыту бер сменада оештырылган; 18 (2015 тә – 17, 2014 тә – 19) муниципаль берәмлекләрдә мәктәп укучылары ике сменада укый. 2015/2016 уку елында 30 852 укучы икенче сменада шөгыльләнгән (8,23 процент), 2016/2017 уку елында – 33 811 укучы (8,78 процент).

Мондый балаларның иң күп өлеше түбәндәге муниципаль берәмлекләрдә: Чистай (33,5 процент), Арча (18,93 процент), Алабуга (15,63 процент), Нурлат (12,28 процент), Зеленодольск (13,68 процент) муниципаль районнары, Казан шәһәре (13,96 процент) һәм Чаллы шәһәре (6,98 процент).

Быел әлеге күрсәткеч Бөгелмә, Лениногорск һәм Нурлат муниципаль районнарында яхшырган.

2014/2015 уку елында Буа муниципаль районында ике сменада укучылар булмаган, ә 2015/2016 уку елында алар барлыкка килгән.

2025 елга кадәр гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны 2017 ел белән чагыштырганда 154 мең кешегә артыр дип көтелә.

Демографик фаразны исәпкә алып, республиканың гомуми белем бирү оешмаларында икенче сменада укучылар өлеше 11,6 процентка кадәр артыр дип көтелә (21 176 кеше).

2016 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яңа урыннар кертүгә ихтыяҗ 22 126 урын дип фаразлана, шул исәптән 2016 – 2020 еллардагы – 14 528 урын (1 таблица):

1 таблица

2016 – 2025 елларга укытуның фаразланган ихтыяҗы һәм заманча шартлар нигезендә Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыру буенча максатчан күрсәткечләр (индикаторлар)

| Т/с | Күрсәткеч (индикатор) исеме | Үлчәү берәмлеге | Күрсәткечнең мәгънәсе | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 1. | Муниципаль районда гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар саны, шул исәптән түбәндәге юллар белән гамәлгә кертелгән: | берәмлек | 800 | 2 948 | 5 772 | 2 624 | 2 384 | 2 224 | 2 124 | 1 400 | 1 190 | 660 |
| 1.2. | гомуми белемнең гамәлдәге инфраструктурасын яңарту (барлыгы), шул исәптән түбәндәге юл белән: | берәмлек | 800 | 2 948 | 5 772 | 2 624 | 2 384 | 2 224 | 2 124 | 1 400 | 1 190 | 660 |
| 1.2.1. | мәктәп биналарын төзү | берәмлек | 800 | 2 948 | 5 772 | 2 624 | 2 384 | 2 224 | 2 124 | 1 400 | 1 190 | 660 |
| 1.3. | мәктәпләрнең тулылыгын оптимальләштерү, инвесторлар җәлеп итү | берәмлек | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми санында бер сменада шөгыльләнүче укучылар санының чагыштырма авырлыгы (барлыгы) | процент | 92,66 | 92,66 | 96,6 | 98,5 | 98,9 | 99 | 99,7 | 99,8 | 100 | 100 |
| 2.1. | башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучылар | процент | 89,8 | 91,7 | 94,5 | 99,5 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 2.2. | төп гомуми белем бирү программалары буенча укучылар | процент | 92,3 | 93,3 | 95,8 | 96,0 | 96,6 | 97 | 99 | 99,8 | 100 | 100 |
| 2.3. | урта гомуми белем бирү программалары буенча укучылар | процент | 95,6 | 97 | 99,6 | 100 | 1000 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |

Сыйфатлы гомуми белемне һәркем алырлык булуны күтәрү өчен гомуми белем бирү оешмаларының 1 – 11 сыйныфларында бер сменалы укыту режимын тәэмин итәргә, шулай ук укучыларны гомуми белем бирү оешмаларының 50 – 70 процент таушалган биналарыннан яңа биналарга күчерергә кирәк.

Ике сменалы укыту бетерү һәм бер сменада укытуны тәэмин итү максатында 2025 елга кадәр түбәндәге төп чараларны үткәрү зарур:

яңа мәктәпләр төзү (36 оешма өчен);

Татарстан Республикасында 50 – 70 процент таушалган тузган мәктәпләрне алыштыру (10 оешма өчен).

Укучыларны 50 – 70 процент таушалган биналардан яңа биналарга күчерү өчен 2016 елдан алып 2020 елга кадәр 1 яңа гомуми белем бирү оешмасы бинасы, 2021 елдан алып 2025 елга кадәр 50 – 70 процент таушалган тузган мәктәпләрне алыштыру өчен 9 яңа гомуми белем бирү оешмасы бинасы төзергә кирәк.

2016 – 2025 елларда бер сменада укытуны тәэмин итү максатында түбәндәге төп чараларны үткәрү зарур (2, 3 таблицалар):

1. Белем бирү процессын оештыруга заманча таләпләргә туры килә торган үрнәк проектларны файдаланып мәктәпләр төзү, бер сменада укытуны оештыру максатында төрле эшчәнлек төрләре өчен файдалану мөмкинлеге бирә торган бүлмәләрне трансформацияләү мөмкинлеге – 26 гомуми белем бирү оешмасы.

2. Укучыларны 50 – 70 процент таушалган биналардан яңа биналарга күчерү өчен белем бирү оешмалары төзү – 10 гомуми белем бирү оешмасы.

2 нче таблица

2016 – 2025 елларга укытуның фаразланган ихтыяҗы һәм заманча шартлары нигезендә яңа урыннар булдыру буенча Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында төп чаралар исемлеге

| Т/с | Чара исеме | Тормышка ашыру вакыты | Үтәүче | Финанслау чыганагы | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Гомуми белем бирүнең 36 яңа объектын төзү | 2016 – 2025 еллар | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты | 22 126 яңа укучы урыны гамәлгә кертү. Гомуми белем бирү оешмаларының 1 – 4 һәм 10 – 11 (12) сыйныфлар укучылары беренче сменада укуга күчә, гамәлдәге бер сменалы укыту режимы саклана. 70 процентган артык таушалган биналарда укучылар яңа мәктәп биналарына күчерелә |

3 нче таблица

«2016 – 2025 елларга Россия Федерациясе субъектларында гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыруга булышлык күрсәтү (фаразланган ихтыяҗдан чыгып)» дәүләт программасы кысаларында 2016 – 2025 елларга укытуның фаразланган ихтыяҗы һәм заманча шартлары нигезендә яңа урыннар булдыру буенча Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында төп чараларны финанслау күләмнәре

(млн.сум)

| Чара исеме, финанслау чыганагы* | 2016 – 2025 елларга финанслау күләмнәре | | | | | | | | | | | Көтелгән нәтиҗә | Программа күрсәткечләре (индикаторлар) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2016 – 2025 еллар – барлыгы | шул исәптән | | | | | | | | | | | |
| | | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| 1. Мәктәп биналарын төзү | 18 559,1 | 508,9 | 2 086,43 | 4 705,68 | 2 076,33 | 1 906,15 | 1 925,45 | 1 875,27 | 1 282,28 | 1 264,79 | 927,82 | Программаны тормышка ашырганда 2025 елга гомуми белем бирү оешмаларының 1 – 4 һәм 10 – 11 (12) сыйныфлар укучылары беренче сменада укуга күчә, гамәлдәге бер сменалы укыту режимы саклана. 70 про- | Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар саны, шул исәптән гомуми белем бирү инфраструктурасы объектларын төзү юлы белән гамәлгә кертелгән. Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның |
| 2. Янкормалар төзү | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | | |
| 3. Мәктәпләрнең тулылыгын оптимальләштерү, инвесторлар җәлеп итү | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | | |
| Барысы | 18 559,1 | 508,9 | 2 086,43 | 4 705,68 | -2 076,33 | 1 906,15 | 1 925,45 | 1 875,27 | 1 282,28 | 1 264,79 | 927,82 | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Программа күрсәткечләре (индикаторлар) | - | 92,66 | 92,66 | 96,6 | 98,5 | 98,9 | 99 | 99,7 | 99,8 | 100 | 100 | центтан артык таушалган биналарда укучылар яңа мәктәп биналарына күчереләә | гомуми санында бер сменада укучылар санының чагыштырма авырлыгы, шул исәптән башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча укучылар. |

*2018 – 2025 елларга акча күләме фараз характерында һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

Укучыларның физик, психологик һәм социаль сәламәтлеген саклау һәм ныгытуны гарантияләүче, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем максатларына ирешүне, аның югары сыйфатын тәэмин итүче белем бирү мохиты тудыру тормышка ашыруның нәтиҗәсе булачак.

Тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча мәктәпләрдә укучыларның барысы да беренче сменада укыячак, 100 процент укучы таушалу дәрәҗәсе югары булган мәктәп биналарыннан яңа мәктәп биналарына күчәчәк.

Татарстан Республикасы буенча тиешле чаралар исемлеге тулысынча һәм муниципаль берәмлекләр буенча адреслап әлеге Ярдәмче программага 5 нче кушымтада китерелгән.»;

Ярдәмче программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3. Ярдәмче программның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү**

Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программа чараларын финанслау күләме 56 038 804,63 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 3 276 380,3 мең сум;
2015 ел – 10 287 192,8 мең сум;
2016 ел – 12 319 020,9 мең сум;
2017 ел – 11 284 218,43 мең сум;
2018 ел – 9 960 996,1 мең сум;
2019 ел – 8 910 996,1 мең сум;
2020 ел – 1 906 155,2 мең сум*;
2021 ел – 1 925 454,4 мең сум*;
2022 ел – 1 875 272,8 мең сум*;
2023 ел – 1 282 280,0 мең сум*;
2024 ел – 1 264 790,0 мең сум*;
2025 ел – 927 828,0 мең сум*.

*2020 – 2025 елларга акча күләме фараз характерында һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

Ярдәмче программаның 5 бүлегендәге таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Күрсәткеч | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрнең гомуми санында мәктәпкәчә белем стандартлары таләпләренә туры килә торган программалар буенча укучы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрнең чагыштырма авырлыгы | 5 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| Төрле оештыру- | 93,7 | 94,3 | 95,6 | 96,7 | 97 | 97,4 | 98 | 98 | 98 | 98 | 98 | 98 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| хокукый формадагы һәм милек формасындагы оешмаларда мәктәпкәчә белем бирү хезмәтен күрсәтүне һәм (яки) аларны карап тоту хезмәтен алучы 3 яшьтән 7 яшькәчә балалар өлеше, процент | | | | | | | | | | | | |
| Яңа федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә укучы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының чагыштырма авырлыгы, процент | 33,1 | 56,6 | 53 | 73 | 73 | 89,2 | 98 | 98 | 98 | 98 | 98 | 98 |
| Биналары авария хәлендә булган яки капиталь ремонт таләп ителгән дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү оешмалары һәм балалар даими булган (муниципаль) гомуми белем бирү оешмалары саны, берәмлек | 380 | 444 | 254 | 190 | 126 | 63 | 63 | 63 | 63 | 63 | 63 | 63 |
| Гомуми белем бирү | 12,8 | 20 | 21,4 | 22 | 22,3 | 22,6 | 22,9 | 22,9 | 22,9 | 22,9 | 22,9 | 22,9 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| оешмаларының гомуми санында инвалид балаларга инклюзив белем бирү өчен универсаль каршылыксыз мохит тудырылган гомуми белем бирү оешмалары өлеше, процент | | | | | | | | | | | | |
| Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының гомуми санында инвалид балаларга инклюзив белем бирү өчен универсаль каршылыксыз мохит тудырылган мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өлеше, процент | – | – | 16 | 17 | 17,5 | 18 | 18 | 18 | 18 | 18 | 18 | 18 |
| 1,5 яшьтән 7 яшькәчә инвалид балаларның гомуми санында мәктәпкәчә белем бирү белән колачланган бу яшьтәге балалар өлеше, процент | – | – | 80 | 85 | 90 | 95 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| Мәктәп яшендәге инвалид балаларның гомуми санында сыйфатлы | – | – | 96 | 97 | 98 | 99 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алу өчен шартлар тудырылган инвалид балалар өлеше, процент | | | | | | | | | | | | |
| 5 яшьтән 18 яшькәчә инвалид балаларның гомуми санында өстәмә белем алучы бу яшьтәге балалар өлеше, процент | – | – | 30 | 35 | 40 | 45 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 |
| Россия Федерациясе субъектында мәгариф оешмаларының гомуми санында инвалид балаларга сыйфатлы белем алу өчен шартлар тудырылган мәгариф оешмалары өлеше, процент | – | – | 13,5 | 14 | 14,5 | 15 | 15,5 | 15,5 | 15,5 | 15,5 | 15,5 | 15,5 |
| Инвалид чыгарылыш укучыларның гомуми санында һөнәри юнәлеш бирү эше белән колачланган 9 һәм 11 сыйныфны тәмамлаучы инвалидлар өлеше, процент | – | – | – | – | 90 | 95 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Муниципаль районда гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар саны, шул исәптән түбәндәге юл белән гамәлгә кертелгән: | – | – | 800 | 2 948 | 5 772 | 2 624 | 2 384 | 2 224 | 2 124 | 1 400 | 1 190 | 660 |
| Гомуми белемнең гамәлдәге инфраструктурасын яңарту (барлыгы), берәмлек | – | – | – | – | – | – | – | – | – | – | – | – |
| мәктәп биналары төзү юлы белән, берәмлек | – | – | 800 | 2 948 | 5 772 | 2 624 | 2 384 | 2 224 | 2 124 | 1 400 | 1 190 | 660 |
| мәктәп биналарына янкорма төзү, берәмлек | – | – | – | – | – | – | – | – | – | – | – | – |
| мәктәпләрнең тулылыгын оптимальләштерү һәм инвесторлар җәлеп итү, берәмлек | – | – | – | – | – | – | – | – | – | – | – | – |
| Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми санында бер сменада шөгыльләнүче укучылар санының чагыштырма авырлыгы (барлыгы), процент, шул исәптән: | – | – | 92,66 | 92,66 | 96,6 | 98,5 | 98,9 | 99 | 99,7 | 99,8 | 100 | 100 |
| башлангыч гомуми белем | – | – | 89,8 | 91,7 | 94,5 | 99,5 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| бирү программалары буенча укучылар санының чагыштырма авырлыгы, процент | | | | | | | | | | | | |
| төп гомуми белем бирү программалары буенча укучылар санының чагыштырма авырлыгы, процент | – | – | 92,3 | 93,3 | 95,8 | 96 | 96,6 | 97 | 99 | 99,8 | 100 | 100 |
| урта гомуми белем бирү программалары буенча укучылар санының чагыштырма авырлыгы, процент | – | – | 95,6 | 97 | 99,6 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| Спорт залларына ремонт ясалган авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны, берәмлек | 30 | 38 | 22 | 14 | – | – | – | – | – | – | – | – |
| Россия Федерациясе субъектында яшәү урыны, социаль һәм мөлкәти статусы, сәламәтлеге торышы, социальләштерү модельләре һәм программалары белән колачлау категорияләре | 90 | 92 | 92,5 | 92,7 | 92,9 | 93 | 93 | 93 | 93 | 93 | 93 | 93 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| буенча балаларның гомуми санында әлеге категорияләр буенча балалар өлеше, процент | | | | | | | | | | | | |
| Тулай торакка мохтаҗларның гомуми санында тулай торак белән тәэмин ителгән укучыларның чагыштырма авырлыгы, процент | 50 | 60 | 70 | 80 | 85 | 90 | 90 | 90 | 90 | 90 | 90 | 90 |
| Һөнәри белем бирү оешмаларының гомуми санында аларны матди-техник тәэмин итүдә эш бирүче оешмалар катнаша торган һөнәри белем бирү оешмалары өлеше, процент | 20 | 25 | 35 | 40 | 50 | 65 | 75 | 75 | 75 | 75 | 75 | 75 |
| Икътисадта эшләүче 25 – 65 яшьләрдәге халыкның гомуми санында һөнәри уку узган әлеге яшь төркемендәге халык санының чагыштырма авырлыгы, процент | 31 | 40 | 43 | 45 | 46 | 48 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 |
| Урта һөнәри белем бирү | – | – | 101 | 102 | 103 | 105 | 107 | 107 | 107 | 107 | 107 | 107 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| программалары буенча укырга кабул ителгән инвалидлар өлеше (узган елга карата), процент | | | | | | | | | | | | |
| Урта һөнәри белем бирү программалары буенча укыган, академик өлгермәү сәбәпле төшеп калган инвалидлар арасыннан студентлар өлеше, процент | – | – | 9 | 8 | 7 | 7 | 7 | 7 | 7 | 7 | 7 | 7 |
| Булган аудиторияләре физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен спорт залларына яңадан профильләнгән авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны, берәмлек | 1 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Укучыларның гомуми санында, мәктәпкәчә белем бирүдән тыш, дәрестән тыш вакытта физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр (баш- | 2,2 | 1,3 | 1,3 | 1,3 | – | – | – | – | – | – | – | – |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| лангыч гомуми белем) өлеше арту, процент | | | | | | | | | | | | |
| Укучыларның гомуми санында, мәктәпкәчә белем бирүдән тыш, дәрестән тыш вакытта физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр (төп гомуми белем) өлеше арту, процент | 2,1 | 1,9 | 1,9 | 1,9 | – | – | – | – | – | – | – | – |
| Укучыларның гомуми санында, мәктәпкәчә белем бирүдән тыш, дәрестән тыш вакытта физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр (урта гомуми белем) өлеше арту, процент | 3,9 | 1,6 | 1,6 | 1,6 | – | – | – | – | – | – | – | – |
| Авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен төзелгән мәктәп спорт клублары саны арту, берәмлек | 56 | 30 | 19 | 11 | – | – | – | – | – | – | – | – |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Авыл җирлегендә урнашкан, аларда ачык яссы корылмалар спорт инвентары һәм җиһазлары белән җиһазландырылган гомуми белем бирү оешмалары саны, берәмлек | 72 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Россия Федерациясе субъектлары гомуми белем бирү оешмаларында федераль бюджет акчасыннан финанслашу исәбеннән гамәлгә кертелгән яңа урыннар саны, берәмлек | – | – | 800 | 2 948 | – | – | – | – | – | – | – | – |
| Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми санында өченче сменада шөгыльләнүчеләрнең чагыштырма авырлыгы, процент | – | – | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Капиталь ремонт яки төзекләндерү таләп ителгән биналарда шөгыльләнүче укучыларның чагыштырма авырлыгы, про- | – | – | – | 8,9 | 8,9 | 8,9 | 8,9 | 8,9 | 8,9 | 8,9 | 8,9 | 8,9 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| цент | | | | | | | | | | | | |
| Барлык төр уңайлыклары булган биналарда укучыларның чагыштырма авырлыгы, процент | – | – | – | 98,99 | 98,99 | 98,99 | 98,99 | 98,99 | 98,99 | 98,99 | 98,99 | 98,99»; |

Ярдәмче программага 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән);

2 нче кушымтаның санлы исемендә «Социаль һәм инженер инфраструктурасын үстерү» сүзләрен «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженер инфраструктураны үстерү» сүзләренә алмаштырырга;

3 нче кушымтаның санлы исемендә «Социаль һәм инженер инфраструктурасын үстерү» сүзләрен «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженер инфраструктураны үстерү» сүзләренә алмаштырырга;

4 нче кушымтаның санлы исемендә «Социаль һәм инженер инфраструктурасын үстерү» сүзләрен «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженер инфраструктураны үстерү» сүзләренә алмаштырырга;

Ярдәмче программага 5 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән);

6 нчы кушымтаның санлы исемендә «Социаль һәм инженер инфраструктурасын үстерү» сүзләрен «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженер инфраструктураны үстерү» сүзләренә алмаштырырга;

7 нче кушымтаның санлы исемендә «Социаль һәм инженер инфраструктурасын үстерү» сүзләрен «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженер инфраструктураны үстерү» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфасын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин